РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Учаллинского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района
ул. Советская, д.51, Азнакаевский район,
с.Учалле, 423317
тел./факс (885592)36-8-32
E-mail: Uchal.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге
башкарма комитеты

Совет ур., 51 нче йорт, Азнакай районы
Үчәлле авылы, 423317
тел./факс (885592)36-8-32
E-mail: Uchal.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«21» декабрь 2022ел** **№35**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 7 апрелендәге 11 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибе турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 7 апрелендәге 11 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибе турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктта «, муниципаль программаларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Муниципаль берәмлек салым чыгымнарының максатчанлыгы критерийлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының муниципаль программаларга

карамаган муниципаль программалар максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына туры килүе;

Ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләр санының һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының 5 еллык чорда нисбәте белән характерлана торган ташламаларга түләүчеләр тарафыннан ихтыяҗ булу.»

1.3. Түбәндәге эчтәлекле 16.1 пунктны өстәргә:

«16.1. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләүне муниципаль берәмлекнең техник салым чыгымнарына карата үткәрмәскә рөхсәт ителә.».

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 7 апрелендәге 11 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибе турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 5 августындагы 21 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары һәм салым чыгымнары исемлеген формалаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» карарын гамәлдән чыгарарга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakavevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Г.М.Төхвәтуллина